РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» март 2020 ел Олы Кайбыч ав. № 221

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Торак кодексының 161 һәм 163 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 28 гыйнварындагы 4-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Үз көчләрен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүенә рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2017 елның 31 июлендәге 85 номерлы карарын;

«Андагы барлык урыннар Кайбыч муниципаль районы милкендә булган күпфатирлы йорт белән идарә итү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының 2013 елның 13 апрелендәге 166 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин